Совет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы района авыл җирлеге Советы

==========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы авылы

22 май 2024 ел № 37/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 23.05.2023 № 27/1 карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә(26.07.2023 № 28/1, 18.12.2023 № 33/2 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**8 статьяның 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:**

«12) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба анкетада булган мәгълүматлар).»;

**11 статьяның 1 пунктының 8 пунктчасы түбәндәге редакциядә бирергә:**

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

**13 статьяның 3 пунктының 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәрә:**

«2) 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;»;

**20 нче маддәнең 2 нче пунктында:**

**а) 11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү**;»**

**б) түбәндәге эчтәлектәге 11_1 пунктчасы белән тулыландырырга:**

11_1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов